2019 ел, ФЕВРАЛЬ

киләчәкне яктырта

# Яшьлек



# Җәннәт әниләрнең аяк астында!





**Исәнмесез, Михаил Яковлевич.**
- Исәнме, кызым (елмая)

**- Сезне кешеләр Бөек Ватан сугышы ветераны буларак беләләр. Шуңа күрә минем сезгә берничә соравым бар иде. Беренче соравым:" Кайда һәм кайчан сез дөньяга килдегез"?**

- Мин 1927 елның 2 маенда Юшады авылында дөньяга килдем. Без гаиләдә 4 бала идек. Әти - әниебез колхозда эшчеләр булып эшләделәр.

**- Бөек Ватан сугышы башланганда сезгә ничә яшь иде?**

- Ул вакытта миңа 14 яшь кенәиде. Мине 1945 елда армиягә озаттылар. Ә аннары армиядән сугышка киттем.

**- Инде сугыш вакытында ашау дигән сүз булмагандыр. Ә чынлап әйткәндә сез ничек туклandыгыз?**


- Безне сугыш вакытында ашатучы булмады. Кайсы ашамлык тапсак, шуны ашадык. Эчергән бәрәңгеләр, ипиләр бик  аз иде.

**- Истә калган мизгел?**

- Бервакыт безне самолетка утырттылар. Инде минем бөтен иптәшләрем парашюттан сикереп төштеләр . Ә мин ....куркам. Берничә минут үткәч мине кемдер төртеп төшерде. Күземне ябып төштем. Бермәлне күземне ачып жибәрсәм, мин инде төшеп җиткәнмен ( көлә).

**-  Бикзур рәхмәт сезгә! Сәламәт булыгыз! Саубулыгыз!**





# Мәхмүт бабаемның Сугышта күргәннәре...

Мәхмүт бабаемның Сугышта күргәннәре...





Сугыш…Ниндидәһшәтле, куркынычсүз. Бухәбәрбөтенкешенететрәндерде. БөекВатансугышытәмамланганга 75 ел вакытүтсәдә, аныңхатирәләрекүңелләргәбиктирәнгәсеңеп калган. ЯзларҗитүбеләнҖиңүбәйрәменбилгеләпүткәндәбувакыйгаларкабатискәтөшә.

Минем бабам да бу сугышта катнашкан. Аның исеме Муллахмәтов Мәхмүт Муллахмәт улы. Ул 1918 елның26 июнендә Минзәлә районы Гөлек авылында дөньяга килә.1937 нче елда Кызыл Армияга алына.1940 нчы елда Кызыл Армиядан кайта. 1941 елны Бөек Ватан сугышы башлана. Бөек Ватан Сугышының беренче көненнән ук бабам сугышка китә. Смоленск шәһәре өчен барган каты сугышларда аягы белән каты яралана. Аны Владимир өлкәсе Гороховец шәһәренә госпитальгә кайтаралар. Анда 3 ай дәвaланганнан соң , тагын сугышка китә. Бу юлы Курск шәһәре янында барган көчле сугышта тагын яралана. Бабаемны Владимир өлкәсе Гусь-Хрустальный шәһәренә госпитольгә кайтаралар. Ул анда 4 ай аягы белән дәвалана. Сугыш давәм итә ул тагын сугышка китә. Аларның гаскәрләре бик күп шәһәрләрне азат итәләр. Сугыш бик озак дәвам итә. Бабаемның гаскәрләре Днепр елгасын бик авырлык белән кичәләр. Елганы кичкән дә аларның көймәләре каплана. Бабам бик авырлык белән генә бу юлы исә кала.
Будапешт шәһәрен, Прага шәһәрен, Көнчыгыш Пруссия дәүләләрен азат итәләр. Австрия ягыннан кереп 8 май 1945 нче елны Австрия дәүләтенең башкаласы Вена шәһәре янында бик каты яралана. Дошман пулясы башын яралый. Аларны санитар поезды белән Уралга Злотоуст шәһәренә кайтаралар. Ул анда 4 ай дәвалана.

Авылга бары 1945 нче елны 29 нчы августында кайтып керә. Сугыштагы батырлыклары өчен аңа Ике Кызыл Йолдыз, Ике Дан орденнары кавалеры, Дурт За Отвагу медальләре белән бүләкләнә.

Кайтуына өйләре җимерелеп беткән , эти-әниләре үлеп беткән. Ашарга юк, киярге юк. Сугыштан соң яшәргә нык авыр була.

Дәү этием бабам турындагы истәлекләрне сөйләгәндә мин сугышның нинди рәхимсез икәнлеген аңладым.Мондый сугышлар кабатланмасын өчен без кулыбыздан килгәннең барын да эшләргә тиешбез.Сугыш белән бернинди мәсьәләләрне дә хәл итеп булмаячагын,әбәлки меңнәрчә гомерләрне,хәтта кешелекне югалтырга мөмкин икәнлекне һәркем аңларга тиеш.

Без ел саен 9 нчы Май көнендә Бөек Җиңүгә багышланган бәйрәм парадын карарга барабыз. Анда күкрәкләренә орден-медальләр таккан чал чәчле ветераннарны күргәч, безгә тыныч тормыш бүләк иткән өчен рәхмәт хисе уяна. Чал чәчләреннән сыйпыйсы, дөньядагы иң матур сүзләр белән юатасы, мең рәхмәт әйтәсе килә аларга!

Бер тормышка күпме сынау, күпме газап китергән бу сугыш. Инде 75 ел үтеп барса да, сугышны онытып булмый. Аны онытырлык түгел!



Айзилә Муллахмәтова

# Укучылар иҗаты!








**Минем бабам – фронтовик**

Дәү бабам сугышта булган
Немец белән сугышкан.
Туган илен саклап калган,
Дошман дигән явыздан.

Медаль-орденнарын аның,
Саклыйбыз без бүген дә.
Сокланабыз без аңа,
Шундый батыр булганга.

Безгә кирәк аның кебек
Батыр булып үсәргә.
Үсеп илне сакларга,
Тынычлыкта яшәргә!

*Заһриев Фәһим, 1 а  класс*

***

Кемнәр ятып калыр иде микән,
Ватаныбыз өчен сугышып?
Кемнәр исән калыр иде микән,
Дөньябызда җиңү булмаса?

Бәлки башкача да булыр иде,
Ләкин шуны истә тотыйк без
Бабаларыбыз җиңү алып кайтты,
Безгә алар аяз күк ачты.

Ничә еллар көннәр үтсәләр дә,
Без аларны искә алабыз.
-Рәхмәт, ветераннар, Җиңү өчен!
Бүләк иткән тормыш өчен рәхмәт!

Маликова Камилә   8 сыйныф



# Җиңүнен 75!









Кулыма каләм алып, әлеге темага язарга алынуыма төрле сәбәпләр этәрде. Җиңүнең 75 еллыгын каршы алырга җыенган көннәрдә, күңелдә әйтеп бетерә алмаслык хисләр уяна. Чөнки әби-бабаларыбыз, дәү эти-әниләребезнең, гомумән, туган халкыбызның Бөек Ватан сугышы елларында һәм аннан соңгы тормышлары турында күбрәк беләсе, исәннәрнең яннарына барып сорашасы, аркаларыннан сөеп рәхмәт әйтәсе килә. Җиңү өчен дип, бар тырышлыкларын куялар. Сугыш бик күп гаиләләргә кайгы, ачы күз яшьләре китерә. Я ире, я уллары, я этиләре Ватан өчен яу кырларында мәңгегә ятып кала. Ачлыктан тилмереп үлүчеләр дә күп була сугыш елларында. Шулай ук фашист концлагерьларында һәлак булучыларның саны да исәпсез. Бу сугышта бик күп якташларыбыз корбан булган. Нинди зур югалтулар!

Ләкин халыкның тырышлыгы бушка китми: күптән көтелгән Җиңү көне килә. Бу көн халкыбыз күңелендә мәңге онытылмас көн булып уелып кала.
Хәзерге вакытта да 9 нчы Май Җиңү көне буларак билгеләп үтелә.
Тик шулай да, күпме еллар узса да, халык хәтерендә Бөек Ватан сугышы иң авыр, иң дәһшәтле сугыш буларак сакланыр, һәм халкыбызның кылган батырлыклары һәрвакыт хөрмәт һәм соклану белән искә алыныр.
Кешелек дөньясы сугышлардан ачы сабак алып, җир йөзендә мәңге тынычлык, бәхет өчен көрәшергә тиеш.



# Батырларны ил онытмас!











**Баш мөхәррир** —Крашева Рузалина
**Әдәби консультант**-Гарипова Рузиля, Мусина Язилә
**Бүлек мөхәррирләре** - Маликова Камилә, Авзалтдинова Камилә, Мулләхмәтова Айзмлә
**Фотокорреспондент**-Яковлева Алсу
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Галиева Лилия Альберт кызы, Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745